Мордовиядә зур күләмдә мошенниклыкта гаепле дип табылган тагын бер жирле кешегә хокем карары чыгарылган.       Прокуратурада сойләүләренчә, Атяшево районында яшәүче 25 яшьлек ир-ат узган ел киеренке түшәмнәр һәм тротуарлар монтажлау белән бәйле эшчәнлеккә 350 мен сум социаль түләү алган. Әмма ул керемнәр турында дорес булмаган мәгълүматлар, шулай ук жиһазлар сатып алу турында ялган документлар тапшырган. Тикшерү вакытында ир-ат зыянны каплаган. Нәтижәдә суд Атяшево кешесенә 140 мен сум штраф салган.
Тагы бер алдау схемасы. Саранскида яшәүче хатын-кыз түләү акчаларынын хокуксыз әйләнешендә шикләнелә.
Нечкәлекләрен тобәк эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәтендә сойләделәр. Узган елнын октябрендә 19 яшьлек шәһәр кешесенә банк картасын 15 менгә сату тәкъдиме белән хәбәр килгән. Кыз ризалаша, паркта ят кеше белән очраша һәм ана түләү чарасын тапшыра. Бүләкләүне ана сонрак вәгъдә иткәннәр, ләкин анын белән бүтән беркем дә элемтәгә кермәгән. Ике айдан сон шикләнелүчегә шундый ук тәкъдим килгән. Ана картага алга таба күчерергә, ә бер олешен үзенә калдырырга кирәк булган акча киләчәген анлаттылар. Кыз кызыксынып, әнгәмәдәшенә үзенен картасы мәгълүматларын һәм пин-кодын хәбәр итте. Нәтижәдә ана 865 меннән артык суммага 17 күчерү кергән. Ләкин ул бернинди операцияләр дә үткәрә алмаган, чонки банк картаны блоклаган.
Шикләнелүчене тоткарлаганнар. Хатын-кыз үз гаебен ул тулысынча таныган.
Сак булыгыз, алданмагыз!